**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№ 44-2** **« 06» декабрь 2024 ел**

«Җир салымы турында» 2023 елның 01 ноябрендәге 31-1 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2023 елның 28 декабрендәге 34-2 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 01 ноябрендәге 31-1 номерлы карарына (2023 елның 28 декабрендәге 34-2 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктының икенче абзацында "(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)" сүзләрен ", эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге абзацта күрсәтелгән ";

1.2. 2.1 пунктның дүртенче абзацында "һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш" сүзләрен өстәргә.;

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән, шулай ук ТР Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында - http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм https://pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүматның рәсми порталында халыкка җиткерелергә тиеш.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы — Ф.В. Мөхәмматов